РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 742** **2015 елның 14 апреле**

# Муниципаль берәмлек чикләрендә тулы яки өлешчә җирле әһәмияттәге юллардан узучы маршрутлар буенча автомобильдә авыр үлчәүле йөк, зур габаритлы йөк ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ Федераль Закон нигезләмәләрен тормышка ашыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки шәһәрара, җирле әһәмиятле автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары нигезендә, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә тулы яки өлешчә җирле әһәмияттәге юллардан узучы маршрутлар буенча автомобильдә авыр үлчәүле йөк, зур габаритлы йөк ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Административ регламентның 1.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга: «Әлеге регламентта билгеләнгән кагыйдәләр, шулай ук автомобиль юлларында күчәргә йөкләнеш чикләү кертү акты белән билгеләнгән иң чик мөмкин булган йөкләнештән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (язгы вакыт) кертелгән чорда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр барышында кулланылырга тиеш».

1.2. Административ регламентның 1.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципаль, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары белән».

1.3. Административ регламентны әлеге карарга кушымта нигезендә редакциядә 4 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында www.e-nizhnekamsk.ru урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.Д. Бит - Мирзага йөкләргә.

Т.Х. Камалетдинов